УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Президентының Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында

Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү буенча эшчәнлекне җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында» 1993 елның 16 апрелендәге ПУ-206 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 1999 елның 9 мартындагы ПУ-147 номерлы, 2000 елның 13 декабрендәге ПУ-979 номерлы, 2001 елның 6 апрелендәге ПУ-265 номерлы, 2005 елның 24 декабрендәге ПУ-514 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-129 номерлы, 2007 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы һәм 2008 елның 20 мартындагы ПУ-120 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре турында нигезләмәнең 2 пункты беренче абзацында:

«Татарстан Фәннәр академиясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» сүзләренә алмаштырырга;

«югары уку йортлары» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре буенча комиссия турында нигезләмәнең 4 пункты «в» пунктчасында «югары уку йортлары» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә 2013 ел Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен бирү турында» 2013 елның 27 ноябрендәге ПУ-1157 номерлы Указының 6 пункты бишенче абзацында «фәнни» сүзен «милли» сүзенә алмаштырырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2013 ел, 16 декабрь
№ ПУ-1232